МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 222/о

П Р И К А З

Б О Е Р Ы К

«14» 12 2015

**Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының капиталь төзелеш объектлары төзелешенә рөхсәтләр бирү өчен дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламентын раслау турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясына, 2010 елның 27 июлендәге “Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры китереп һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 06 июлендәге “Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре” хакында 313 номерлы карары нигезендә **боерык бирәм**:

1. Кушымта булып килүче Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының капиталь

төзелеш объектлары төзелешенә рөхсәтләр бирү өчен дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламентны расларга.

2. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю. Латыйповага законнарда билгеләнгән тәртиптә шушы боерыкның дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына һәм “Татарстан Республикасының дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр реестры” дәүләт мәгълүмат системасын алып баручы вәкаләтле органга җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторы җитәкчесе Г.С. Миңнехановага Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынганнан соң ун эш көне дәвамында әлеге Боерыкның “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2012 елның 10 августындагы “Административ регламентларны раслау турында” 127/о номерлы боерыгының 1 пунктындагы икенче абзацын, 2 пунктын көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту җаваплылыгын үз өстемә алам.

ОТДЕЛ РЕГЛАМЕНТА И КОНТРОЛЯ №1

**Министр** **И.Ә.Фәйзуллин**

Татарстан Республикасы
Төзелеш, архитектура һәм
торак-коммуналь хуҗалык
министрлыгының 2015 елның
“14” 12 №222/0
боерыгы белән расланды

# Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының капиталь төзелеш объектлары төзелешенә рөхсәтләр бирү өчен дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Административ регламент (алга таба – Административ регламент), Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының 5 һәм 5.1 өлешләрендә һәм башка федераль законнарда билгеләнгән очраклардан кала, капиталь төзелеш объектын төзү ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль район, шәһәр округы) территориясендә планлаштырылган очракта һәм ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль район, шәһәр округы) территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектын үзгәртеп корган очракта капиталь төзелеш объектлары төзелешенә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели (алга таба – дәүләт хезмәте).

1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар: юридик һәм физик затлар, шәхси эшмәкәрләр, шулай ук аларның законлы вәкилләре (алга таба – мөрәҗәгать итүче яки төзүче).

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

Дәүләт хезмәтен үтәүче – Министрлыкның архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенең территорияләрне планлаштыру һәм төзү бүлеге (алга таба – Бүлек).

1.3.1. Министрлык урнашкан урын: Казан ш., Дзержинск ур, 10 й.

Бүлек урнашкан урын: Казан ш., Кремль ур., 13, 3 кат., каб. К302.

Министрлыкның эш графигы:

дүшәмбе – пәнҗешәмбе: 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр,

җомга: 9.00 сәгатьтән 16.45 сәгатькә кадәр,

шимбә, якшәмбе: ял көннәре.

Төшке аш: 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Керү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ нигезендә.

1.3.2. Бүлекнең белешмә телефоннары: 231-15-16, 231-15-43, 231-14-64.

1.3.3. “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендә (алга таба – “Интернет” челтәре) Министрлыкның рәсми сайт адресы: http://www.minstroy.tatar.ru.

Министрлыкның электрон почта адресы: msagkh@tatar.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) Министрлыкның мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә

урнаштырылган, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст рәвешендәге мәгълүматларны үз эченә алган, дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмати элмә такталар аша;

2) “Интернет” челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында (http://www.minstroy.tatar.ru);

Татарстан Республикасының дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) Министрлыкка язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ рәвешендә).

1.3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтында һәм Министрлыкның мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендәге мәгълүмати элмә такталарда урнаштырыла.

1.3.6. Мәгълүмати элмә такталарда урнаштырыла торган мәгълүмат дәүләт хезмәте турындагы шушы Административ регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган белешмәләрне үз эченә ала;

1.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеш кодексы (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2005, № 1 (1 өлеше), 16 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба – РФ ШрК);

Россия Федерациясенең Җир кодексы (алга таба – РФ ҖК) (Собрание Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2001, № 44, 4147 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә исәпкә алып);

2010 елның 27 июлендәге “Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 210-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон);

2015 елның 06 апрелендәге “Хуҗалык җәмгыятьләренең мөһер зарурлыгын гамәлдән чыгару өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү турында” 82-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 82-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2015, № 14, 2022 ст.);

Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 07 маендагы “Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында” 601 номерлы Указы (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2012, № 19, 2338 ст.) (алга таба – 601 номерлы РФ Президенты Указы);

Россия Федерациясе Региональ үсеш министрлыгының 2011 елның 10 маендагы “Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы рәвешен раслау турында” 207 номерлы боерыгы (“Российская газета”, № 122, 08.06.2011);

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2015 елның 19 февралендәге “Төзелешкә рөхсәт рәвешен һәм объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт рәвешен раслау турында” 117/пр номерлы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru -

13.04.2015).

2010 елның 25 декабрендәге “Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында” 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш), 1453 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба – 98-ТРЗ номерлы ТР Законы);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 06 июлендәге “Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре” турында 313 номерлы Карары белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы турында нигезләмә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы, 2005, № 28, 0642 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба – Министрлык турында нигезләмә);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 02 ноябрендәге “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында” 880 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба – 880 номерлы ТР МК карары).

1.5. Бу Административ регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр шуларга нигезләнеп кертелгән документлардагы мәгълүматларның (дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе) төгәлсезлегенә китергән хата (язу хатасы, хәреф хатасы грамматик яки арифметик хата);

дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә мөрәҗәгать итүчеләрдән документларны кабул итеп алу һәм бирү, аларны консультацияләү.

Әлеге Административ регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә аңлашыла (2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясының 1 пункты). Гаризаның киңәш ителә торган рәвеше шушы Административ регламентка карата 1,2 кушымтада китерелә.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы | Стандартка карата таләпнең эчтәлеге | Хезмәтне яки таләпне билгели торган норматив акт |
| --- | --- | --- |
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының 5 һәм 5.1 өлешендә һәм бүтән федераль законнарда билгеләнгән очраклардан кала, капиталь төзелеш объектын төзү ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль район, шәһәр округы) территориясендә планлаштырылган очракта һәм ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль район, шәһәр округы) территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектын үзгәртеп корган очракта капиталь төзелеш объектлары төзелешенә рөхсәтләр бирү | РФ ШрК 55 ст.<br>Министрлык турында нигезләмә |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче башкарма хакимият органы аталышы | Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | Раздел 3 Положения о Министерстве |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Төзелешкә рөхсәт;<br>төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын озайту;<br>төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү;<br>төзелешкә рөхсәт бирүдән баш тарту турында белдерүнамә;<br>төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын озайтудан баш тарту турында белдерүнамә;<br>төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында белдерүнамә. | РФ ШрК 51 ст. |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, туктату мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату вакыты | 1. Төзелешкә рөхсәт бирү яисә бирүдән баш тарту (төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын озайту) процедураларын башкару вакыты төзелешкә рөхсәт бирү (төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын озайту) турында гариза теркәлгән көннән соң 10 эш көненнән дә артык түгел.<br>2. Төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү яисә төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән баш тарту процедураларын башкару вакыты мөрәҗәгать итүчедән яки төзүчедән аларга җир кишәрлекләренә карата хокуклар, җир асты байлыкларыннан файдалану хокуклары күчү турында, җир кишәрлеге булдыру турында белдерүнамә теркәлгән көннән башлап | РФ ШрК 51 ст. |

| | | |
|---|---|---|
| | 10 эш көненнән дә артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату каралмаган. | |
| 2.5. Законнар яки бүтән норматив-хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен кирәкле булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны бирү тәртибе | 2.5.1. Төзелешкә рөхсәт бирү, төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын озайту турында гариза, шулай ук җир кишәрлекләренә карата хокуклар, җир асты байлыкларыннан файдалану хокуклары күчү һәм бир кишәрлеген булдыру турында белдерүнамә (алга таба – хокук күчү турында белдерүнамә) мөрәҗәгать итүче (аның вәкаләтле вәкиле) тарафыннан шәхсән яки почта аша хат итеп Министрлык адресына тапшырыла. Хокуклар күчү турында гариза яки белдерүнамә кулдан, машинада басу ысулы белән яки компьютердан файдаланып тутырыла һәм мөһер булган очракта мөрәҗәгать итүченең мөһере белән таныклана. | РФ ШрК 51 ст.<br>82-ФЗ номерлы Федераль закон |
| | 2.5.2. Төзелешкә рөхсәт бирү турында, төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын озайту турында гариза, шулай ук хокук күчү турында белдерүнамә шушы Административ регламентка карата 1 нче, 2 нче кушымталарда китерелгән үрнәктә тутырыла.<br>Гаризада һәм белдерүнамәдә түбәндәгеләр күрсәтелергә тиеш: әлеге гариза кая бирелә (Министрлыкка); юридик затлар яисә шәхси эшмәкәрләр өчен - аталышы, оешу-хокукый рәвеше, салым түләүченең тәңгәллек номеры (алга таба - ИНН); юридик һәм почта адреслары; җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме; телефон; банк реквизитлары (банкның аталышы, исәп-хисап счеты, корреспондент счеты, банкның индивидуаль коды (алга таба - р/с, к/с, БИК)); физик затлар өчен - Ф.И.О., яшәү урыны, шәхесен таныклый торган документ белешмәләре. | РФ ШрК 51 ст. |
| | 2.5.3. Төзелешкә рөхсәт бирү турында һәм төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын озайту турында гаризаларда түбәндәгеләр күрсәтелергә тиеш:<br>- объектның аталышы һәм адресы; объектта планлаштырыла торган эшләрнең төре (төзү, үзгәртеп кору яки капиталь ремонт) һәм алар гамәлгә ашырылачак вакыт (төзелешне оештыру проекты нигезендә); капиталь төзелеш объекты төзелешенә, үзгәртеп корылышына яки капиталь ремонтына проект документациясен эшләгән проект оешмасының аталышы; проект-смета документациясе кем тарафыннан, кайчан һәм | РФ ШрК 51 ст. |

| | |
|---|---|
| кайсы номер белән теркәлү турында мәгълүмат; дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе реквизитлары; подряд оешмасын, аның милекчелек рәвешләрен һәм банк реквизитларын күрсәтеп, подряд эшләрен башкаруга карата дәүләт контракты номеры һәм датасы; подряд оешмасының, таныклык биргән органны күрсәтеп, капиталь төзелеш объектларының иминлегенә йогынты ясый торган эшләргә кертелүе турында таныклык номеры һәм датасы; эшләр башкару өчен җаваплы зат (Ф.И.А., белеме, төзелештәге эш стажы) турында мәгълүмат һәм аны билгеләү турында боерык; объектның төп күрсәткечләре (проект-смета документациясеннән); РФ ШрК нигезендә гаризага теркәлә торган документлар исемлеге; имза, дата, мөрәҗәгать итүченең вәкиле булган затның Ф.И.А. һәм вазифасы. | |
| Төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын озайту турында гаризада һәм хокук көчү турында белдерүнамәдә төзелешкә бирелгән рөхсәтнең датасы һәм номеры күрсәтелергә тиеш. | РФ ШрК 51 ст. |
| 2.5.4. Хокук көчү турында белдерүнамәдә түбәндәгеләрнең реквизитлары күрсәтелергә тиеш:<br>1) хокуклар җир кишәрлекләренә карата көчкәндә, мондый җир кишәрлекләренә карата хокук билгели торган документларның;<br>2) җир кишәрлекләрен булдыру турында карарның, әгәр җир турындагы законнар нигезендә җир кишәрлеген булдыру турында карарны башкарма хакимиятнең башкарма органы яки җирле үзидарә органы кабул итсә, түбәндәге очракларда:<br>аларга яки аларның берсенә карата төзелешкә рөхсәт бирелгән җир кишәрлекләрен берләштерү юлы белән җир кишәрлеге булдырганда;<br>аларга карата төзелешкә рөхсәт бирелгән җир кишәрлекләрен бүлү, бүлеп бирү яки аннан аерып чыгару юлы белән җир кишәрлекләре булдырылганда;<br>3) җир кишәрлекләрен бүлү, бүлеп бирү яки җир кишәрлекләреннән аерып чыгару юлы белән булдырган очракта капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору планлаштырыла торган җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планының;<br>4) җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын бирү турында карарның һәм җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензияне яңадан | РФ ШрК 51 ст. |

| | | |
|---|---|---|
| | рәсмиләштерү турында карарның. | |
| | 2.5.5. Төзелешкә рөхсәт бирү турында гаризага түбәндәгеләр теркәлә:<br>1) җир кишәрлегенә хокук билгели торган документлар;<br>2) җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы яки, линияле объект төзелешенә рөхсәт бирелгән очракта, территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты реквизитлары;<br>3) проект документациясендә булган материаллар:<br>а) аңлатма язуы;<br>б) капиталь төзелеш объектын урнаштыру, аңа килү һәм керү урыннарын, гавами сервитутларның гамәлдә булу зоналары чикләрен, археология мирасы объектларын күрсәтеп, җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы нигезендә башкарылган җир кишәрлеген планда оештыру схемасы;<br>в) линияле объектның кызыл линияләр чикләрендә урнашуын раслый торган, линияле объектларга карата территорияләрне планлаштыру буенча кулланыла торган документация составында расланган җир кишәрлеген планда оештыру схемасы;<br>г) архитектур чишелешләрне чагылдыра торган схемалар<br>д) инженерия ягыннан җиһазлау турында белешмәләр, проектлана торган капиталь төзелеш объектын инженерлык-техник тәэминат челтәрләренә тоташтыру урыннарын күрсәтеп, инженерлык-техник тәэминат челтәрләренең җыелма планы; | РФ ШрК 51 ст. |
| | е) капиталь төзелеш объекты төзелешен оештыру проекты;<br>ж) капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен сүтү яки демонтажлау буенча эшләрне оештыру проекты;<br>4) әгәр проект документациясе РФ ШрК 49 ст. нигезендә экспертизага тиешле булса, капиталь төзелеш объектының проект документациясенә карата уңай экспертиза бәяләмәсе (РФ ШрК 48 ст. 12.1 өлешендә каралган очракта төзелешнең аерым этапларына карата кулланыла), РФ ШрК 49 ст. 3.4 өлешендә каралган очракларда проект документациясенә карата уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсе, РФ ШрК 49 ст. 6 өлешендә каралган очракларда проект документациясенә карата уңай дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсе; | |

| | | |
|---|---|---|
| | 5) рөхсәт ителгән төзелешнең, үзгәртеп коруның чик параметрларыннан читләшүгә рөхсәт (әгәр дә төзүчегә мондый рөхсәт РФ ШрК 40 ст. нигезендә бирелгән булса);<br>6) мондый объектны үзгәртеп корган очракта, капиталь төзелеш объектына карата барлык хокук ияләренең ризалыгы;<br>7) проект документациясенә карата дәүләти булмаган экспертизасы бәяләмәсе тапшырылган очракта, проект документациясенә карата уңай дәүләти булмаган экспертиза бәяләмәсен биргән юридик затның аккредитациясе турында таныклык күчермәсе.<br>Гаризага проект документациясенә карата дәүләти булмаган экспертиза бәяләмәсе теркәлергә мөмкин.<br>Төзелешкә рөхсәт алу өчен кирәкле булган документлар бер нөсхәдә (чын нөсхәсе яки күчермәсе) яисә ике нөсхәдә тапшырыла, аның берсе чын нөсхәсе, икенчесе оешма тарафыннан таныкланган күчермә булырга тиеш. Документларны икешәр нөсхәдә тапшырган очракта, тикшергәннән соң чын нөсхәләре мөрәҗәгать итүчегә кайтарып бирелә. | |
| | 2.5.6. Төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын озайту турында карар кабул итү өчен түбәндәге документлар кирәк:<br>1) төзү вакытлары өлешендә төзәтмәләр кертелгән капиталь төзелеш объекты төзелешен оештыру проекты;<br>2) дәүләт төзелеш күзәтчелеге тарафыннан аны алу турында тамгалап, капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору буенча эшләр башлану турында төзүченең хәбәрнамәсе күчермәсе.<br>Хокук күчү турында белдерүнамәгә мөрәҗәгать итүче шушы Административ регламентның 2.5.5 пунктында күрсәтелгән документларның күчермәләрен теркәргә хокуклы. | РФ ШрК 51 ст. |
| 2.6. Норматив-хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, | Шушы Административ регламентның 2.5.5 пунктының 1, 2 һәм 5 пунктчаларында күрсәтелгән документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр), әгәр мөрәҗәгать итүче аталган документларны мөстәкыйль тапшырмаса, Министрлык тарафыннан аталган документлар алар карамагында булган дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалардан соратып алына. | РФ ШрК 51 ст. |

| | | |
|---|---|---|
| шулай ук аларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны бирү тәртибе | Шушы Административ регламентның 2.5.5 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән документлар, әгәр күрсәтелгән документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) Күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның бердәм дәүләт реестрында булмаса, мөрәҗәгать итүче (төзүче) тарафыннан мөстәкыйль җибәрелә. | |
| 2.7. Норматив-хокукый актларда каралган очракларда дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен алар белән килештерү таләп ителә торган һәм бу килештерү дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләренең исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | РФ ШрК 51 ст. |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр юк | РФ ШрК 51 ст. |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату яки аны күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>1. Төзелешкә рөхсәт бирүдән баш тарту нигезләре булып түбәндәгеләр санала:<br>шушы Административ регламентның 2.5.5 пунктында каралган документлар булмау; тапшырылган документларның җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы таләпләренә яки, линияле объект төзелешенә рөхсәт биргәндә, территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты таләпләренә, шулай ук рөхсәт ителгән төзелешнең, үзгәртеп коруның чик параметрларыннан читләшүгә бирелгән рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве.<br>2. Төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын озайтудан баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:<br>шушы Административ регламентның 2.5.6 пунктында каралган документлар булмау;<br>капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору эшләре мондый гаризаны тапшыру вакыты узганчы (төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу | РФ ШрК 51 ст. |

| | | |
|---|---|---|
| | вакыты узганчыга кадәр кимендә 60 көн алдан) башланмаса.<br>3. Төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән баш тарту нигезләре:<br>1) хокук көчү турындагы белдерүнамәдә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының 21.10 өлешендәге 1-4 пунктларында тиешенчә каралган документларның реквизитлары булмау яки, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының 21.13 өлешендә күрсәтелгән очракта, җир кишәрлегенә карата хокук билгели торган документ булмау;<br>2) хокук көчү турында белдерүнамәдә күрсәтелгән белешмәләрнең дөрес булмавы;<br>3) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының 21.7 өлешендә каралган очракта, капиталь төзелеш объектын планда урнаштыруның җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы таләпләренә туры килмәве.<br>4. Мөрәҗәгать итүче юридик зат федераль яки региональ башкарма хакимият органы булмаган очракта, төзелешкә бирелгән рөхсәтләр реестрыннан мәгълүмат бирүдән баш тартылырга тиеш.<br>5. Мөрәҗәгать итүче Министрлык вәкаләтләренә керми торган төзелешкә рөхсәт бирү турында гариза җибәргән очракта, Бүлек белгечләре мөрәҗәгать итүчегә төзелешкә рөхсәт бирүдән (төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын озайтудан, төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән) баш тарту турындагы белдерүнамәне хат итеп җибәрә яки имзалатып тапшыра. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт пошлинасының яки бүтән төрле түләүләрне алу тәртибе, аларның күләме һәм аларны алу нигезләре | Дәүләт хезмәте бушлай нигездә күрсәтелә. | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәткән өчен түләүләр алу тәртибе, аларның күләме һәм аларны алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплап чыгару методикасы | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |

| | | |
|---|---|---|
| турындагы мәгълүматны да кертеп | | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә тапшырганда һәм мондый хезмәтләрне күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты | Мөрәҗәгать итүченең кабул итүне (хезмәт күрсәтелүне) максималь көтү вакыты 15 минуттан артып китәргә тиеш түгел.<br>Дәүләт хезмәтен алучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гарызнамәсен, шул исәптән электрон рәвештә теркәү вакыты | Гариза Министрлыкка кергән көнне. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга карата, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урынына, мондый хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедия мәгълүматларын урнаштыруга һәм формалаштыруга карата таләпләр | бина түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:<br>мөрәҗәгать итүченең һәм вәкаләтле бүлекчәдәге вазифаи затның уңайлы урнашуын;<br>мөрәҗәгать итүчегә кирәкле документларны рәсмиләштерү мөмкинлеге һәм җайлылыгы;<br>телефон элемтәсе;<br>документларның күчермәсен алу мөмкинлеге;<br>язу-сызу кирәк-яракларының һәм А4 рәвешендәге кәгазь булу. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең үтемлелек һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазифаи затлар белән хезмәттәшлек итү саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәтен дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәктә, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникация | Дәүләт хезмәтенең үтемлелек күрсәткечләре булып түбәндәгеләр санала:<br>Министрлык бинасының җәмәгать транспорты өчен дәүләт үтемлелеге зонасында урнашуы;<br>белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган биналарның кирәкле күләмдә булуы;<br>мәгълүмати элмә такталарда, Министрлыкның “Интернет” челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында дәүләт хезмәте күрсәтүнең ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында тулы мәгълүмат булу.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелүнең сыйфаты түбәндәгеләрнең булмавы белән сыйфатлана:<br>мөрәҗәгать итүчеләрдән документларны кабул итеп алганда һәм биргәндә чират булмау;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү вакытларын бозу;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтүче дәүләт хезмәткәрләренең гамәлләренә | 880 номерлы ТР МК карарының 2.4 пункты, 601 номерлы РФ Президенты Указы |

| | | |
|---|---|---|
| технологияләреннән файдаланып | (гамәл кылмауларына) карата шикаятьләр;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтүче дәүләт хезмәткәрләренең тупас, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр.<br>Мөрәҗәгать итүченең Бүлек белгечләре белән хезмәттәшлек итү күләме:<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган гаризаны һәм документларны турыдан-туры тапшырганда һәм дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсен турыдан-туры алганда – ике мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>Мөрәҗәгать итүче белән хезмәттәшлек итү озынлыгы – 15 минуттан артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтү буенча күпфункцияле үзәктә (алга таба - КФҮ), КФҮ читтән торып эшләү урынында күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә алынырга мөмкин.<br>Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелү барышы турында мәгълүматны “Интернет” челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтыннан, Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында алу мөмкинлеге тормышка ашырылмаган. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон рәвештә, шул исәптән дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан файдаланып күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны электрон рәвештә “Татарстан Республикасы Хөкүмәте порталы” мәгълүмат системасы – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Порталының интернет-кабул итү системасы аша тапшыру мөмкинлеге бар. Министрлыкка Татарстан Республикасы Хөкүмәте порталының интернет-кабул итү системасы аша җибәрелгән гаризаларны кабул итү, теркәү һәм карау Министрлыкның 2007 елның 23 мартындагы “Татарстан Республикасы Хөкүмәте Порталының “Интернет-кабул итү” системасының функцияләү регламентын раслау турында” гы 74/о номерлы боерыгында каралган тәртиптә башкарыла.<br>Гаризаны Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша яки Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшыру мөмкинлеге тормышка ашырылмаган. | |

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләрнең читтән торып эшләү урыннарында үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау.

3.1.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган гаризаны тутырганда һәм документларны рәсмиләштергәндә;

2) гаризаларны кабул итү һәм теркәү;

3) гаризаны карау һәм тапшырылган документларның комплектлылыгын тикшерү;

4) ведомствоара гарызнамәләрне формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

5) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен әзерләү;

6) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен мөрәҗәгать итүчегә бирү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү гамәлләренең эзлеклелеге буенча блок-схема әлеге Административ регламентка карата 3 нче кушымтада китерелә.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган гаризаны тутырганда һәм документларны рәсмиләштергәндә ярдәм күрсәтү.

Дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация алу өчен мөрәҗәгать итүче вәкаләтле бүлекчәгә язмача рәвештә, Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталындагы Интернет-кабул итү аша (http://www.minstroy.tatar.ru) электрон рәвештә яки вазифаи затка шәхси мөрәҗәгать итү рәвешендә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле булган документларның составы, рәвеше һәм эчтәлеге буенча һәм мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә.

Бу пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле булган документларның составы, рәвеше һәм эчтәлеге һәм рөхсәт алуның бүтән мәсьәләләре буенча консультацияләү һәм мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә.

3.3. Төзелешкә рөхсәтләр бирү турында, төзелешкә рөхсәтләрнең гамәлдә булу вакытларын озайту турында һәм төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында гаризаларны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән үзе, ышанычлы заты тарафыннан яки почта аша дәүләт хезмәте күрсәтелү турында гариза тапшыра һәм шушы Регламентның 2.5 пункты нигезендә документларны Министрлыкның оештыру эше һәм эш башкару бүлегенә тапшыра.

3.3.2. Министрлыкның оештыру эше һәм эш башкару бүлеге белгече гаризаны һәм документларны, шулай ук хокук көчү турында белдерүнамәне Министрлыкның Эш башкару күрсәтмәләре нигезендә терки һәм карап тикшерү өчен вәкаләтле бүлекчәгә (алга таба - Бүлек) җибәрә.

Дәүләт хезмәтен электрон рәвештә күрсәтү турында гариза Бүлеккә электрон почта яки Интернет-кабул итү аша җибәрелә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар документлар Министрлыкка кергән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: теркәлгән гариза һәм документлар.

3.3.3. Дәүләт хезмәтен башкару вазифасы йөкләнгән Бүлекнең вазифаи затлары (алга таба – Бүлек белгечләре) төзелешкә рөхсәтләр бирү (төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын озайту, төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү, хокук көчү турында белдерүнамәләр) турында гаризаларны теркәү дәфтәрен (алга таба – Дәфтәр) алып бара.

Дәфтәрдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

мөрәҗәгать итүче тарафыннан документларны тапшыру датасы (Министрлыкка керү датасы);

мөрәҗәгать итүченең аталышы;

вәкаләтле бүлекчәнең документларны кабул иткән вазифаи затының фамилиясе һәм инициаллары;

объектның аталышы һәм кергән документларның кәгазьләр (папкалар, тартмалар һ.б.) саны;

төзелешкә рөхсәт әзерләү датасы;

мөрәҗәгать итүчегә төзелешкә рөхсәт бирү (төзелешкә рөхсәт бирүдән баш тарту) яки почта аша җибәрү датасы;

төзелешкә рөхсәт (документларын теркәп, төзелешкә рөхсәт бирүдән баш тарту) алган затның имзасы;

төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын озайту турында карар әзерләү датасы;

мөрәҗәгать итүчегә төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын озайту (төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын озайтудан баш тарту) турында белдерүнамә тапшыру яки почта аша җибәрү датасы;

төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында карар әзерләү датасы;

мөрәҗәгать итүчегә төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү (төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән баш тарту) турында белдерүнамә тапшыру яки почта аша җибәрү;

искәрмә.

Дәфтәр әлеге Административ регламентка карата 5 кушымтага туры китереп, кулъязма һәм электрон рәвештә алып барыла.

Бүлек белгечләре кергән гариза турында белешмәләрне Дәфтәргә теркиләр.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны һәм документларны Министрлыкта теркәгән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Дәфтәрдә теркәлгән язу.

3.4. Гаризаны карау һәм тапшырылган документларның тулы булу-булмавын тикшерү.

3.4.1. Бүлек белгечләре тапшырылган документларның тулы булу-булмавын әлеге Административ регламентның 2.5 пунктындагы таләпләргә туры китереп тикшерә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар тапшырылган гаризаны теркәгән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырылган документларның тулы булу-булмавын билгеләү.

3.4.2. Шушы Административ регламенттагы таләпләр нигезендә төзелешкә рөхсәт алу, төзелешкә рөхсәтнең гамәлдәге вакытын озайту һәм төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү, мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлык вәкаләтләренә керми торган төзелешкә рөхсәт бирү турында гариза җибәрү өчен кирәкле булган, гаризага теркәлә торган документларның исемлеге тулы булмаган очракта, Бүлек белгечләре мөрәҗәгать итүчегә, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, төзелешкә рөхсәт бирүдән (төзелешкә рөхсәтнең гамәлдәге вакытын озайтудан, төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән) баш тарту турында Министрлыкның вәкаләтле вазифаи заты имзалаган белдерүнамәне хат аша җибәрә яки имзалатып кулга тапшыра һәм Дәфтәрдә тиешле язу терки.

Төзелешкә рөхсәт бирүдән (төзелешкә рөхсәтнең гамәлдәге вакытын озайтудан, төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән) баш тарту турында белдерүнамә белән берлектә мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкаләтле вәкилләренә) ул тапшырган барлык документлар да кайтарып бирелә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң 3 эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: төзелешкә рөхсәт бирүдән баш тарту һәм мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү.

3.5. Ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру һәм аларны дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү.

3.5.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта (әлеге Административ регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документлар тапшырылганда) Бүлек белгечләре, шушы Административ регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документлар исемлеге нигезендә белешмәләр алу өчен дәүләт хезмәтләре күрсәтүче, муниципаль хезмәтләр күрсәтүче, дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы органнарга, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга, ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү процессында катнашучы бүтән дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм оешмаларга ведомствоара гарызнамә җибәрә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Административ регламентның 3.4.1 пунктындагы процедура тәмамланганнан соң 1 эш көне

дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тиешле органнарга җибәрелгән гарызнамәләр.

3.5.2. Электрон хезмәттәшлек итү процессында катнашучы органнар билгеләнгән срокта шушы Административ регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар электрон хезмәттәшлек итү процессында катнашучы органга гарызнамә кергән көннән соң 3 эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: гарызнамәләргә җаваплар яки мәгълүмат юклыгы турында белдерүнамә.

3.6. Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсен әзерләү.

3.6.1. Бүлек белгечләре проект документациясенең җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы таләпләренә, яисә, линияле объект төзелешенә рөхсәт бирелгән очракта – территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты таләпләренә, шулай ук кызыл линияләргә туры килүен тикшерәләр. Мөрәҗәгать итүчегә рөхсәт ителгән төзелешнең яки үзгәртеп коруның чик параметрларыннан читләшүгә рөхсәт бирелгән очракта проект документациясенең яки җир кишәрлеген планда оештыру схемасының рөхсәт ителгән төзелешнең яки үзгәртеп коруның чик параметрларыннан читләшүгә рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә туры килүе тикшерелә.

Тапшырылган документациянең түбәндәгеләргә туры килүе тикшерелә:

1) җир кишәрлегенең түбәндәгеләрне билгели торган шәһәр төзелеше планында билгеләнгән параметрларына:

а) җир кишәрлегенең чикләре;

б) гавами сервитутларның гамәлдә булу зонасы чикләре;

в) чикләрендә биналар, төзелмәләр, корылмалар төзү тыела торган биналарны, төзелмәләрне, корылмаларны урнаштырырга мөмкин булган урыннарны ачыклау максатларында җир кишәрлегенең чикләреннән минималь чигенүләр;

г) җир кишәрлегеннән рөхсәтле файдалану турында мәгълүмат;

д) күрсәтелгән җир кишәрлегендә капиталь төзелеш объектын билгеләүгә, аның параметрларына һәм урнаштырылуына карата таләпләр;

е) җир кишәрлеге чикләрендә урнашкан капиталь төзелеш объектлары, мәдәни мирас объектлары турында мәгълүмат;

ж) капиталь төзелеш объектларын инженерлык-техник тәэминат челтәрләренә тоташтыруның техник шартлары турында мәгълүмат;

з) капиталь төзелеш объектларын дәүләти яки муниципаль ихтыяҗлар өчен планда урнаштыруны зонасы чикләре;

2) территорияне планлаштыру составында расланган кызыл линияләр.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Административ регламентның 3.5.1 процедурасы тәмамланганнан соң 5 эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тикшерелгән проект документациясе.

3.6.2. Тапшырылган документлар шәһәр төзелеше планы таләпләренә,

территорияне планлаштыру проекты составында расланган кызыл линияләргә, шулай ук рөхсәт ителгән төзелешнең яки үзгәртеп коруның чик параметрларыннан читләшүгә рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә туры килмәгән очракта, Бүлек белгечләре, Министрлыкның вәкаләтле вазифаи затының имзасы белән, баш тартуның сәбәпләрен күрсәтеп, төзелешкә рөхсәт бирүдән баш тарту турында белдерүнамә әзерлиләр һәм мөрәҗәгать итүче (аның вәкаләтле вәкиле) адресына җибәрәләр.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң 1 эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән төзелешкә рөхсәт бирүдән баш тарту турында хат.

3.6.3. Төзелешкә рөхсәт бирү өчен җаваплы булган Бүлек белгечләре, тапшырылган документлар шәһәр төзелеше планы таләпләренә, территорияне планлаштыру проекты составында расланган кызыл линияләргә, шулай ук рөхсәт ителгән төзелешнең яки үзгәртеп коруның чик параметрларыннан читләшүгә рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә туры килгән очракта:

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2015 елның 19 февралендәге “Төзелешкә рөхсәт рәвешен һәм объектны эксплуатациягә кертү өчен рөхсәт рәвешен раслау турында” 117/пр номерлы боерыгы белән расланган рәвештә төзелешкә рөхсәт әзерлиләр. Төзелешкә бирелгән рөхсәт ике нөсхәдә әзерләнә, аның берсе мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкаләтле вәкиленә) тапшырыла, икенчесе Министрлык архивында саклана. Төзелешкә бирелгән рөхсәт әлеге Административ регламентның 4 нче кушымтасына туры китереп, Төзелешкә бирелгән рөхсәтләр реестрында (алга таба – Реестр) тәртип саны белән исәпкә алына;

гаризада күрсәтелгән элемтә ысулыннан файдаланып, мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкаләтле вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен турында хәбәр итәләр, рәсмиләштерелгән рөхсәтне бирү датасы һәм вакыты турында җиткерәләр;

төзелешкә рөхсәт бирү турында карарны Дәфтәрдә теркиләр.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар документларның законнардагы таләпләргә туры килүен тикшергәч һәм капиталь төзелеш объектын караганнан соң (әлеге Административ регламентның 3.6.1 пунктындагы процедуралар тәмамлангач) 2 эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: төзелешкә әзерләнгән рөхсәт, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкаләтле вәкиленә) хәбәр итү.

3.6.4. Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкаләтле вәкиленә), төзелешкә бирелгән рөхсәтләр дәфтәрендә рөхсәт алу турында имзалатып, төзелешкә рөхсәт тапшыра.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар чират тәртибендә мөрәҗәгать итүче килгән көнне 15 минут дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: төзелешкә бирелгән рөхсәт.

3.6.5. Төзелешкә бирелгән рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын озайту,

вакытлыча туктатып тору һәм туктау шәһәр төзелеше турында законнар һәм әлеге Административ регламентның 3.3.2-3.6.4 пунктлары таләпләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

Төзелешкә бирелгән рөхсәтнең гамәлдә булу вакыты Министрлык карары буенча, рөхсәтнең гамәлдә булу вакыты беткәнчегә кадәр мөрәҗәгать итүченең 60 көннән дә соңга калмыйча тапшырылган гаризасы булганда, проект документациясенең бер кисәге булган, төзәтмәләр кертелгән төзелешне оештыру проектында күрсәтелгән срокка озайтылырга мөмкин.

Әгәр төзелеш, үзгәртеп кору төзелешкә бирелгән рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын озайту турында гариза тапшыру вакыты узганчыга кадәр башланмаган икән, Министрлык төзелешкә бирелгән рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын озайтудан баш тарта.

3.7. Административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре.

3.7.1. Электрон рәвештә түбәндәге административ процедуралар башкарыла ала:

төзелешкә рөхсәт бирү өчен документларны кабул итү;

тапшырылган документларны карап тикшерү;

төзелешкә бирелгән рөхсәтләрне исәпкә алу.

3.7.2. Гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны, шулай ук хокук күчү турында белдерүнамәне мөрәҗәгать итүче шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнарда һәм шушы Административ регламентта куела торган таләпләрне үтәп, электрон рәвештә тапшыру хокукына ия.

Документлар электрон рәвештә тапшырылган очракта гариза һәм аңа теркәлә торган документлар, шулай ук хокук күчү турында белдерүнамә гаризаны имзалаган затның электрон санлы имзасы белән таныкланырга тиеш

3.7.3. Гаризага мөрәҗәгать итүче тапшырган документларның исемлеге, шулай ук, мондый мөмкинлекне бирә торган юридик нигезләрне күрсәтеп, тапшырылмый торган документларның исемлеге теркәлә.

Тапшырылмый торган документлар исемлегендә аларның аталышлары, аларны биргән органнар, теркәлү номерлары, аерым очракларда – алардагы тиешле гарызнамәләрне бирү өчен кирәкле булган белешмәләр күрсәтелә.

3.8. техник хаталарны төзәтү

3.8.1. Хезмәт нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта мөрәҗәгать итүчегә Бүлеккә түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (6 нчы кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә хезмәт нәтиҗәсе буларак бирелгән һәм техник хатасы булган документ;

юридик көчкә ия булган, техник хата барлыгы турында таныклый торган документлар.

Хезмәт нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдәге техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (аның вәкаләтле вәкиле) тарафыннан шәхсән тапшырыла, яисә почта аша (шул исәптән электрон почтадан файдаланып) җибәрелә.

3.8.2. Документларны кабул итү өчен җаваплы булган белгеч техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә, теркәлгән документлары белән берлектә гаризаны терки һәм аларны Бүлеккә тапшыра.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгәннән соң бер көн дәвамында башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, карап тикшерү өчен Бүлек белгеченә җибәрелгән гариза.

3.8.3. Бүлек белгече документларны карап тикшерә һәм, хезмәт нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатларында, шушы Регламентның 3.6.3 пунктында каралган процедураларны башкара һәм төзәтелгән документны мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкаләтле вәкиленә), мөрәҗәгать итүчедән (аның вәкаләтле вәкиленнән) техник хатасы булган документның төп нөсхәсен алып, шәхсән имзалатып тапшыра яки мөрәҗәгать итүченең адресы буенча почта аша (электрон почта ярдәмендә) Бүлеккә техник хатасы булган документның төп нөсхәсен тапшырганда документны алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура техник хатаны ачыклаганнан соң яки теләсә нинди кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза алынгач өч көн дәвамында башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.

3.9. Дәүләт хезмәте КФҮ, КФҮнең читтән торып эшләү урынында күрсәтелми.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Министрлыктагы вазифаи затлар тарафыннан шушы Административ регламенттагы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган бүтән норматив-хокукый актлардагы нигезләмәләренең саклануын һәм үтәлешен, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул ителүен агымдагы контрольдә тоту тиешле административ процедура үтәлеше өчен җаваплы булган зат тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.2. Агымдагы контроль Министрлыктагы вазифаи затлар тарафыннан шушы Административ регламенттагы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган бүтән норматив-хокукый актлардагы нигезләмәләренең саклануын һәм үтәлешен тикшерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы контроль даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелүнең тулы һәм сыйфатлы булуын контрольдә тоту тикшерүләр үткәрүне, мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очракларын ачыклауны һәм бетерүне, мөрәҗәгать итүчеләрнең Министрлыктагы вазифаи затларның карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаятьтән торучы мөрәҗәгатьләрен карап тикшерүне, карарлар кабул итүне һәм җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтелүнең тулы һәм сыйфатлы булуын тикшерүләр Министрлыкның актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Тикшерүләр планлы (Министрлыкның яртыеллык яки еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырылырга) һәм планнан тыш булырга мөмкин.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтелүнең тулы һәм сыйфатлы булуына карата планнан тыш тикшерү үткәрү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Административ регламенттагы һәм бүтән норматив-хокукый актлардагы дәүләт хезмәтен күрсәтүгә карата таләпләр билгели торган таләпләрне бозуның элек ачыкланган очракларын бетерүне тикшерү сәбәпле;

2) Министрлыкның дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы вазифаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата физик һәм юридик затларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылуга карата мөрәҗәгатьләр булганда.

4.6. Дәүләт хезмәте күрсәтелүнең тулы һәм сыйфатлы булуын тикшерү нәтиҗәләре акт белән рәсмиләштерелә, анда ачыкланган җитешсезлекләр һәм аларны бетерү буенча тәкъдимнәр теркәлә.

4.7. Контрольлек нәтиҗәләре буенча, мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу ачыкланган очракта, гаепле затларны Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тарту гамәлгә ашырыла.

4.8. Дәүләт хезмәте күрсәтелүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан контрольдә тоту дәүләт хезмәте күрсәткәндә Министрлык эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүмат алу һәм мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) дәүләт хезмәте күрсәтелү процессында судка кадәр карап тикшерү мөмкинлеге булу юлы белән гамәлгә ашырыла.

## 5. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүче вазифаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмавын) судка кадәр (судтан тыш) шикаять кылу тәртибе

5.1. Дәүләт хезмәтен алучылар дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Идарә (бүлек) хезмәткәрләренең гамәлләрен (гамәл кылмавын) судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә Идарә (бүлек) җитәкчесенә шикаять кылырга хокуклы.

Идарә (бүлек) җитәкчесе кабул иткән карарларга карата шикаятьләр Министрлыкка тикшереп торучы министр урынбасары яки министр исеменә тапшырыла, министр урынбасары (министр) тарафыннан кабул ителгән карарлар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына шикаять кылынырга мөмкин.

5.2. Мөрәҗәгать итүче түбәндәге очракларда да шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелү турындагы гарызнамәсен теркәү срогы бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтелү срогы бозылганда;

мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында каралмаган документлар таләп ителгәндә;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында аларны тапшыру каралган документларны кабул итүдән баш тартканда;

әгәр дә баш тарту нигезе федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда;

дәүләт хезмәтен яки муниципаль хезмәтне күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазифаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартканда яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозганда.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача рәвештә яки электрон рәвештә бирелә.

Шикаять почта аша, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең КФҮ аша, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайты (http://minstroy.tatarstan.ru/), Татарстан Республикасының дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы (https://uslugi.tatar.ru/), Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы (http://www.gosuslugi.ru/) аша бирелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү барышында кабул итеп алынырга мөмкин.

5.4. Мөрәҗәгатьне карау вакыты – аны теркәгәннән соң унбиш эш көне дәвамында һәм, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазифаи заты мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартканда яки мондый төзәтмәләрнең билгеләнгән срогын бозуны шикаять кылган очракта, – аны теркәгәннән соң биш эш көне дәвамында.

5.5. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) шикаять кылына торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазифаи затының яки дәүләт хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр яисә мөрәҗәгать итүче исеменнән эш йөртүче мөрәҗәгать итүче- юридик затның аталышы, урнашу урыны турында белешмәләр. Шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган электрон почта (булган очракта) адресы (адреслары) һәм почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазифаи затының яки дәүләт хезмәткәренең шикаять кылына торган карарлары

һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазифаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карары һәм гамәле (гамәл кылмавы) белән риза булмау нигезләренә дәлилләр.

5.6. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре теркәлергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлә торган документларның исемлеге күрсәтелә.

5.7. Шикаять аны тапшыручы дәүләт хезмәте алучы зат тарафыннан имзалана.

5.8. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча шушы регламентның 5.1 пунктында күрсәтелгән вазифаи зат түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә аларны алу Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында каралмаган акчаларны кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук бүтән рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Шушы пунктта күрсәтелгән карарны кабул итү көненнән соң килүче көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача рәвештә яки мөрәҗәгать итүченең теләге буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында җавап җибәрелә.

5.9. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять кылу составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү буенча вәкаләтләр бүлеп бирелгән вазифаи зат кичекмәстән булган материалларны прокуратура органнарына җибәрә.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура
һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының
капиталь төзелеш объектлары төзелешенә рөхсәтләр
бирү өчен дәүләт хезмәте күрсәтү буенча
административ регламентына
1 нче кушымта

кемгә: Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы
кемнән:_____________________________________________
(юридик зат – төзүне, үзгәртеп коруны

_____________________________________________________________________
гамәлгә ашыруны планлаштыручы төзүченең аталышы;

_____________________________________________________________________
ИНН; юридик һәм почта адреслары;

_____________________________________________________________________
җитәкчесенең ФИА; телефоны;

_____________________________________________________________________
банк реквизитлары (банкның аталышы, р/с, к/с, БИК)

# Төзелешкә рөхсәт бирү турында гариза

_____________________________________________________________________________ адресы буенча җир кишәрлегендәге
(шәһәр, район, урам, кишәрлек номеры)

_____________________________________________________________________________________________
(объектның аталышы)

_____________________________________________________________________________________________

_____________________________________________________________________________________________

төзелешенә/үзгәртеп корылышына ___________________ айга кадәр рөхсәт бирүне сорыйм.
(кирәклесенең астына сызарга)

Төзелеш (үзгәртеп кору) ______ елның “____”_______________ №_____________ __________________________________
(документның исеме)

нигезендә гамәлгә ашырылачак.

Җирдән файдалану хокукы ______ елның “____”_______________ №_____________ __________________________________
(документның исеме)

нигезендә беркетелде.

Объект төзелешенә карата проект документациясе түбәндәге тарафыннан эшләнде _____________________________________

_____________________________________________________________________________________________
(проект оешмасының аталышы, ИНН, юридик һәм почта адреслары,

_____________________________________________________________________________________________
җитәкчесенең ФИА, телефон номеры, банк реквизитлары

_____________________________________________________________________________________________
(банкның аталышы, р/с, к/с, БИК))

ул проект эшләрен башкаруга хокуклы, әлеге хокук ___________ елның “_____”______________________________№__________

_____________________________________________________________________________________________
(документның исеме һәм аны биргән вәкаләтле оешманың аталышы)

нигезендә беркетелгән һәм билгеләнгән тәртиптә кызыксынган оешмалар һәм архитектура һәм шәһәр төзелеше органнары белән килештерелде:

- дәүләт экспертизасы буенча алынган уңай бәяләмә: № ______________ “___”______________ ел.
- җир кишәрлеген планда оештыру схемасы түбәндәге белән килештерелде ___________________________________________ № ________ “___”_____________ ел.

(оешманың аталышы)

Проект документациясе расланды ________________________________________________________________

_____________________________________ № ________ “___”_________________ ел.

Өстәмә мәгълүмат бирәбез:

Төзелешне (үзгәртеп коруны) финанслау түбәндәгечә башкарылачак________________________________________

_____________________________________________________________________________________________
(банк реквизитлары һәм счет номеры)

Эшләр подряд (хуҗалык) ысулы белән 20___ елның “____”____________ №______ шартнамә нигезендә гамәлгә ашырылачак.

_____________________________________________________________________________________________
(оешманың аталышы, ИНН,

_____________________________________________________________________________________________
юридик һәм почта адреслары, житәкчесенең ФИА, телефон номеры,

_____________________________________________________________________________________________
банк реквизитлары (банкның аталышы, р/с, к/с, БИК))

Төзү-монтажлау эшләрен башкару хокукы _______елның “_____”________________№______________________________

_____________________________________________________________________________________________
(документның һәм аны биргән оешманың аталышы)

______________________________________________________________нигезендә беркетелде.

Эшләрне башкаручы итеп ________елның «___»___________ № ________ боерыгы нигезендә махсус ____________ белеме һәм
(югары/урта)

төзелештә _____ел стажы булган _________________________________ билгеләнде.
(вазифасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Төзелеш контрольлеге ______ елның «___» ___________№_____ шартнамә нигезендә ________________________

_____________________________________________________________________________________________
(оешманың исеме, ИНН, юридик һәм почта адресы, житәкчесенең ФИА,

_____________________________________________________________________________________________
телефон номеры, банк реквизитлары (банкның аталышы, р/с, к/с, БИК)

тарафыннан башкарылды,
заказчы (төзүче) функцияләрен башкару хокукы _________ елның «_____»__________ №_________
_____________________________________________________ нигезендә беркетелде.
(документның һәм аны биргән оешманың исеме)

Әлеге гаризада китерелгән белешмәләргә бәйле барлык үзгәрешләр турында ________________________________
(вәкаләтле органның аталышы)

хәбәр итү вазифасын үз өстемә алам.

______________________ ___________________ _______________________________
(вазифа) (имза) (Ф.И.А.)

“____”______________20____ ел.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура
һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының
капиталь төзелеш объектлары төзелешенә рөхсәтләр
бирү өчен дәүләт хезмәте күрсәтү буенча
административ регламентына
2 нче кушымта

кемгә: Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы
кемнән:_______________________________________________
(юридик зат – төзүне, үзгәртеп коруны

_______________________________________________________________
гамәлгә ашыруны планлаштыручы төзүченең аталышы;

_______________________________________________________________
ИНН; юридик һәм почта адреслары;

_______________________________________________________________
җитәкчесенең ФИА; телефоны;

_______________________________________________________________
банк реквизитлары (банкның аталышы, р/с, к/с, БИК)

## Төзелешкә бирелгән рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын озайту турында гариза

_____________________________________________________________________________ адресы буенча җир кишәрлегендәге
(шәһәр, район, урам, кишәрлек номеры)

_______________________________________________________________________________________________
(объектның аталышы)

_______________________________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________________________

төзелешенә/үзгәртеп корылышына бирелгән рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын_________ айга кадәр озайтуны сорыйм.
(кирәклесенең астына сызарга)

Төзелеш (үзгәртеп кору) ______ елның "____"_______________ №_____________ ________________________________
(документның исеме)
нигезендә гамәлгә ашырылачак.

Җирдән файдалану хокукы ______ елның "____"_______________ №_____________ ________________________________
(документның исеме)
нигезендә беркетелде.

Объект төзелешенә карата проект документациясе түбәндәге тарафыннан эшләнде ______________________________________

_______________________________________________________________________________________________
(проект оешмасының аталышы, ИНН, юридик һәм почта адреслары,

_______________________________________________________________________________________________
җитәкчесенең ФИА, телефон номеры, банк реквизитлары

_______________________________________________________________________________________________
(банкның аталышы, р/с, к/с, БИК))

ул проект эшләрен башкаруга хокуклы, әлеге хокук ___________ елның "_____"______________________________№__________

_______________________________________________________________________________________________
(документның исеме һәм аны биргән вәкаләтле оешманың аталышы)

нигезендә беркетелгән һәм билгеләнгән тәртиптә кызыксынган оешмалар һәм архитектура һәм шәһәр төзелеше органнары белән килештерелде:

- дәүләт экспертизасы буенча алынган уңай бәяләмә: № ______________ "___"______________ ел.
- җир кишәрлеген планда оештыру схемасы түбәндәге белән килештерелде

__________________________________________ № ________ "___"_____________ ел.
(оешманың аталышы)

Проект документациясе расланды ______________________________________________________________

_____________________________________ № ________ "___"_________________ ел.

Өстәмә мәгълүмат бирәбез:

Төзелешне (үзгәртеп коруны) финанслау түбәндәгечә башкарылачак_____________________________________________
____________________________________________________________________________________________________________
(банк реквизитлары һәм счет номеры)

Эшләр подряд (хуҗалык) ысулы белән 20___ елның "____"____________ №______ шартнамә нигезендә гамәлгә ашырылачак.

____________________________________________________________________________________________________________
(оешманың аталышы, ИНН,
____________________________________________________________________________________________________________
юридик һәм почта адреслары, җитәкчесенең ФИА, телефон номеры,
____________________________________________________________________________________________________________
банк реквизитлары (банкның аталышы, р/с, к/с, БИК))

Төзү-монтажлау эшләрен башкару хокукы _______елның "_____"________________№________________________________
____________________________________________________________________________________________________________
(документның һәм аны биргән оешманың аталышы)

____________________________________________________________нигезендә беркетелде.

Эшләрне башкаручы итеп ________елның «___»___________ № ________ боерыгы нигезендә махсус ____________ белеме һәм
(югары/урта)

төзелештә _____ел стажы булган _______________________________ билгеләнде.
(вазифасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Төзелеш контрольлеге ______ елның «___» ___________№_____ шартнамә нигезендә _______________________
____________________________________________________________________________________________________________
(оешманың исеме, ИНН, юридик һәм почта адресы, җитәкчесенең ФИА,
____________________________________________________________________________________________________________
телефон номеры, банк реквизитлары (банкның аталышы, р/с, к/с, БИК)

тарафыннан башкарылды,
заказчы (төзүче) функцияләрен башкару хокукы _________ елның «_____»__________ №_________
__________________________________________________ нигезендә беркетелде.
(документның һәм аны биргән оешманың исеме)


Әлеге гаризада китерелгән белешмәләргә бәйле барлык үзгәрешләр турында ______________________________
(вәкаләтле органның аталышы)

хәбәр итү вазифасын үз өстемә алам.

| | | |
|---|---|---|
| ____________________ | __________________ | ______________________________ |
| (вазифа) | (имза) | (Ф.И.А.) |

"_____"____________________20___ ел.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының капиталь төзелеш объектлары төзелешенә рөхсәтләр бирү өчен дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламентына 3 нче кушымта



Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура
һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының капиталь төзелеш объектлары төзелешенә рөхсәтләр бирү өчен дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламентына
4 нче кушымта

## Капиталь төзелеш объектлары төзелешенә бирелгән рөхсәтләр реестры

| № п/п | Керүче документның номеры һәм датасы | Мөрәҗәгать итүченең аталышы | Объектның аталышы | Рөхсәтнең датасы һәм номеры | Рөхсәтнең гамәлдә булу вакыты | Чыгучы документның номер һәм датасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура
һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының
капиталь төзелеш объектлары төзелешенә рөхсәтләр
бирү өчен дәүләт хезмәте күрсәтү буенча
административ регламентына
5 нче кушымта

## Төзелешкә рөхсәтләр бирү (төзелешкә бирелгән рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын озайту) турында гаризаларны теркәү дәфтәре

| № п/п | Мөрәҗәгать итүче тарафыннан документларны тапшыру датасы (Министрлыкка керү датасы) | Мөрәҗәгать итүченең аталышы | Структур бүлекчәнең документларны кабул иткән вәкаләтле вазифаи затының фамилиясе һәм инициаллары | Объектның аталашы һәм кергән документларны кәгазь (папкалар, тартмалар h.б.) саны | Төзелешкә рөхсәтне әзерләү датасы/ *төзелешкә бирелгән рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын озайту турында карар әзерләү датасы/* төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында карар әзерләү датасы | Мөрәҗәгать итүчегә төзелешкә рөхсәт (төзелешкә рөхсәт бирүдән баш тарту) тапшыру датасы яки почта аша җибәрү датасы/ *мөрәҗәгать итүчегә төзелешкә бирелгән рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын озайту (төзелешкә бирелгән рөхсәтнең гамәлдәге вакытын озайтудан баш тарту турында) белдерүнамә тапшыру датасы яки почта аша җибәрү датасы/* мөрәҗәгать итүчегә төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү (төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән баш тарту) турында белдерүнамә тапшыру датасы яки почта аша җибәрү датасы | Төзелешкә рөхсәт (төзелешкә рөхсәт бирүдән баш тарту) алган затның имзасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының капиталь төзелеш объектлары төзелешенә рөхсәтләр бирү өчен дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламентына 6 нчы кушымта

кемгә: Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы

кемнән:___________________________________________

(юридик зат – төзүне, үзгәртеп коруны

_______________________________________________

гамәлгә ашыруны планлаштыручы төзүченең аталышы;

_______________________________________________

ИНН; юридик һәм почта адреслары;

_______________________________________________

житәкчесенең ФИА; телефоны;

_______________________________________________

банк реквизитлары (банкның аталышы, р/с, к/с, БИК)

## Техник хатаны төзәтү турында гариза

_______________________________________________________________________

(хезмәтнең исеме)

дәүләт хезмәтен күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм.

Болай дип язылган:_____________________________________________

_______________________________________________________________________

_______________________________________________________________________

Дөрес белешмәләр:_____________________________________________

_______________________________________________________________________

_______________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм тиешле үзгәрешләрне дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документка кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

3.

Техник хатаны төзәтү турында гаризаны кире каккан очракта мондый карарны түбәндәгечә җибәрүне сорыйм:

электрон документ җибәрү юлы белән шушы E-mail адресына:_______;

кәгазьдә, түбәндәге адреска почта аша: _____________________________________________________________________.

Хәзергесе белән раслыйм: гаризага теркәлгән, минем шәхесемә һәм

минем вәкаләтле вәкиләмә кагыла торган, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән белешмәләр дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килә, гаризаны тапшыру вакытына әлеге документлар гамәлдә һәм дөрес белешмәләрдән тора.

_______________ __________________ ( _________________)

(дата) (имза) (Ф.И.А.)

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының капиталь төзелеш объектлары төзелешенә рөхсәтләр бирү өчен дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламентына 7 нче кушымта

**Дәүләт хезмәтен күрсәтү һәм аның үтәлешен контрольдә тоту өчен җаваплы булган вазифаи затларның реквизитлары**

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы

| Вазифасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Министрның беренче урынбасары | **231-14-05** | A.AS@tatar.ru |
| Министр урынбасары | **231-15-07** | Vladimir.Kudryashev@tatar.ru |
| Идарә башлыгы | **231-15-57** | G.Zagidullina@tatar.ru |
| Бүлек башлыгы | **231-15-16** | Olga.Kaynova@tatar.ru |
| Бүлек белгечләре | **231-14-64**<br>**231-14-28** | Lyudmila.Sibatrova@tatar.ru<br>Irina.Valeeva@tatar.ru<br>I.Nigmatullina@tatar.ru<br>V.Z.I@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазифасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсенең юл һәм төзелеш комплексларында инвестиция программаларын тормышка ашыру буенча бүлек башлыгы | **264-77-24** | Yuriy.Azin@tatar.ru |